Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаш иавыл җирлеге башлыгы

25 ноябрь 2019 ел № 32

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Ямаш авыл җирлегенең
Нолинка авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Нолинка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 07 декабрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ямаш авыл җирлегенең Нолинка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү ечен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: юлларны норматив хәлгә китерүгә?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча урнашкан йорт янында уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Нолинка авылы, Лесная урамы, 3 нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү кененә кадәр 10 кеннән дә соңга калмыйча, Нолинка авылы, Лесная урам, 3 нчы йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) кененнән үз кеченә керә.

Ямаш авыл җирлеге башлыгы А.И. Чуркин